ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

10 ноябрь, 2024 ел № 38/4

«2025- 2027 елларга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең чик (максималь) индекслары турында» Татарстан Республикасы Рәисе Указы проектын килештерү хакында

«Россия Федерациясендә гражданнарның коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләмен үзгәртү индексларын формалаштыру турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 30 апрелендәге 400 номерлы карарының 43 пунктында билгеләнгән тәртип нигезендә,

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

«2025 - 2027 елларга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең чик (максималь) индекслары турында» Татарстан Республикасы Рәисе Указы проектын килештерергә (кушымтада).

Шәһәр Хакиме
вазыйфаларын башкаручы И.А. Сәгыйдуллина

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

Шәһәр Советының
38/4 Карарына кушымта
10 ноябрь, 2024 ел

Проект

**2025 - 2027 елларга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең чик (максималь) индекслары турында**

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен гражданнарның түләү күләмен үзгәртү индексларын формалаштыру турында» 2014 елның 30 апрелендәге 400 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның _ ________________ номерлы күрсәтмәсе нигезендә **карар бирәм**:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең Татарстан Республикасында коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләменең Татарстан Республикасында уртача рөхсәт ителгән иң чик тайпылыш күләменнән артып киткән үзгәрешеннән иң чик (максималь) индексының 2025 - 2027 еллар чорына планлаштырылучы күрсәткечләрен расларга (кушымта).

2. Әлеге Указ кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Татарстан Республикасы
Рәисе Указына
кушымта
_______ , 2024 ел № ___

**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең Татарстан Республикасында коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләменең Татарстан Республикасында уртача рөхсәт ителгән иң чик тайпылыш күләменнән артып киткән үзгәрешеннән иң чик (максималь) индексының 2025 - 2027 еллар чорына планлаштырылучы күрсәткечләре**

| Муниципаль берәмлек | Ел | Планлаштырылучы күрсәткеч (процент) |
|---|---|---|
| город Набережные Челны | 01.01.2025 - 30.06.2025 | 0 |
| | 01.07.2025-31.12.2025 | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 30 апрелендәге 400 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнарга түләү күләменең үзгәрү индексларын формалаштыру нигезләренең 43 пункты нигезендә (алга таба – индекслар формалаштыру нигезләре) гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр өчен кертелә торган түләү күләменең үзгәрүенең чик (максималь) индексын (алга таба – чик индекс) билгеләү турындагы акт проектында планлаштырыла торган күрсәткечләрнең чик индексы түбәндәге формулада күрсәтелә: $$ПЗПИ_g^{МО} = ИКУ_g^{суб} + ИС_g^{МО},$$ монда: |

| Муниципаль берәмлек | Ел | Планлаштырылучы күрсәткеч (процент) |
|---|---|---|
| | | $ПЗПИ_g^{МО}$ – чик индексның планлаштырылучы күрсәткече (процент);<br><br>$ИКУ_g^{суб}$ – Татарстан Республикасы буенча уртача индекс (процент);<br><br>$ИС_g^{МО}$=4,9% – «Чаллы су каналы» ҖЧҖ инвестиция программасын гамәлгә ашыруга инвестиция өлеше (процент) |
| | 01.01.2026 - 30.06.2026 | 0 |
| | 01.07.2026 - 31.12.2026 | Индекслар фомалаштыру нигезләренең 43 пункты нигезендә чик индексны билгеләү турындагы акт проектында планлаштырыла торган күрсәткечләрнең чик индексы түбәндәге формулада күрсәтелә:<br><br>$ПЗПИ_g^{МО} = ИКУ_g^{суб} + ИС_g^{МО}$,<br><br>монда:<br><br>$ПЗПИ_g^{МО}$ — чик индексның планлаштырылучы күрсәткече (процент);<br><br>$ИКУ_g^{суб}$ – Татарстан Республикасы буенча уртача индекс (процент);<br><br>$ИС_g^{МО}$=5,9% – «Чаллы су каналы» ҖЧҖ инвестиция программасын гамәлгә ашыруга инвестиция өлеше (процент) |
| | 01.01.2027-30.06.2027 | 0 |

| Муниципаль берәмлек | Ел | Планлаштырылучы күрсәткеч (процент) |
|---|---|---|
| | 01.07.2027-31.12.2027 | Индекслар фомалаштыру нигезләренең 43 пункты нигезендә чик индексны билгеләү турындагы акт проектында планлаштырыла торган күрсәткечләрнең чик индексы түбәндәге формулада күрсәтелә: $$ПЗПИ_g^{МО} = ИКУ_g^{суб} + ИС_g^{МО},$$ монда: $ПЗПИ_g^{МО}$ — чик индексның планлаштырылучы күрсәткече (процент); $ИКУ_g^{суб}$ – Татарстан Республикасы буенча уртача индекс (процент); $ИС_g^{МО}$=6,2% – «Чаллы су каналы» ҖЧҖ инвестиция программасын гамәлгә ашыруга инвестиция өлеше (процент) |